Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2019 нчы елның 9 нчы августы 255№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Советының 2016 нчы елның 19 нчы
апрелендәге 30 номерлы "Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы территориясендә
җәмәгать сервитутларын билгеләү һәм туктату
тәртибе турында" карарына үзгәрешләр кертү хакында

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Җир кодексының 5 статьясына тәңгәлләштереп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 нче елның 12 нче августындагы 660 номерлы "Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә җәмәгать сервитутлар билгеләү һәм туктату тәртибе турында" карарының 2 пункты нигезендә Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2016 нчы елның 19 нчы апрелендәге 30 номерлы "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә җәмәгать сервитутларын билгеләү һәм туктату тәртибе турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Россия Федерациясе җир законнары нигезендә Әлки муниципаль районы территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренә карата Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә җәмәгать сервитутлар (алга таба - җәмәгать сервитуты) билгеләү һәм туктату процедуралары җайга салына, мәнфәгатьләрендә җир кишәрлекләренә карата ачык сервитутлар билгеләү һәм туктату процедуралары әлеге тәртиптә Россия Федерациясе җир законнары нигезендә җайга салына, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегендә каралган очраклардан тыш.";

- 3 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"җир кишәрлеге аша узу яисә йөрү, шул исәптән гомуми файдаланудагы су объекты янына һәм аның яр буе полосасына гражданнарның ирекле үтүен тәэмин итү максатларында;";

- 3 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) җир кишәрлегендә ызан тамгаларын, дәүләт геодезия челтәрләренең геодезия пунктларын, гравиметрик пунктларны, нивелир пунктларны һәм аларга керү юлларын урнаштыру.;";

- 3 пунктның 8 пунктчасында “балыкчылык” сүзләреннән соң “аквакультура (балыкчылык)" сүзләрен өстәргә;

- 3 пунктның 2, 9 һәм 10 пунктчалары үз көчләрен югалткан дип танырга;

- 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы мәнфәгатьләрен тәэмин итүче җәмәгать сервитутларны билгеләү һәм туктату, шул исәптән ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына үзгәрешләр кертү белән бәйле чыгымнарның күләмле түләвен түләү өчен , җир кишәрлегенә хокук иясенең чыгымнарын каплау белән бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.”;

- 17 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать сервитутын туктату турындагы карары, шул исәптән вакытыннан алда да, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында җәмәгать сервитутын туктату турындагы язма язылу көненнән үз көченә керә”;

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми http://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль районы Башлыгы А. Ф. Никошин